ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ЫК ТАМАГЫ АВЫЛЫ
ГРАЖДАННАРЫ ҖЫЕНЫ

КАРАР

17.12.2022 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылы гражданнары җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

2023 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Ык Тамагы авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум, 1-2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, балигъ булмаган балалары булган гаиләләр, көндезге уку формасы студентлары, Россия армиясендә вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә.

2. Үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

- вак таш сатып алу һәм китертү
- Вак ташны тигезләү буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү
- Кышкы чорда юлларны кардан чистарту
- Җәяүлеләр яр буеннан су буена төшү юлын төзекләндерү, территорияне төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов